ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Миграция законнарындагы үзгәрешләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы территориясендә чит ил гражданнарының хезмәт эшчәнлеге өлешендә Россия Федерациясе миграция сәясәтенең актуаль мәсьәләләре турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Э.Ә. Зарипованың һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре буенча идарәсе башлыгы М.Ш. Галиевның, миграция законнарындагы үзгәрешләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы территориясендә чит ил гражданнарының хезмәт эшчәнлеге өлешендә Россия Федерациясе миграция сәясәтенең актуаль мәсьәләләре турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Э.Ә. Зарипованың һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре буенча идарәсе башлыгы М.Ш. Галиевның, миграция законнарындагы үзгәрешләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы территориясендә чит ил гражданнарының хезмәт эшчәнлеге өлешендә Россия Федерациясе миграция сәясәтенең актуаль мәсьәләләре турындагы мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты белән бергә хезмәт миграциясе өлкәсендәге Россия Федерациясе законнарын мониторинглау һәм аларны актуальләштерү буенча үз вакытында тәкъдимнәр әзерләү эшен дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Чит ил хезмәткәрләрен яңа социаль, икътисадый, хокукый шартларга, рус телен һәм мәдәниятен, Россия тарихын һәм Россия Федерациясе законнары нигезләрен өйрәнүне дә кертеп, яраклаштыру һәм интеграцияләү барышында аларга ярдәм күрсәтүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыруны дәвам итәргә.

3.2. Чит ил хезмәткәрләренә һәм аларның гаилә әгъзаларына ирекле медицина иминияте программаларын тарату һәм төрле милек рәвешендәге предприятиеләр белән бергә аларга аренда торагын бирү механизмнарын эшләү юлы белән чит ил хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының социаль яклануын арттыру мәсьәләләрен эшләргә.

3.3. Хезмәт миграциясе өлкәсендә дәүләт тарафыннан тикшереп торуны гамәлгә ашырганда һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәткәндә мәгълүмат технологияләрен киң дәрәҗәдә гамәлгә кертү нигезендә миграция агымнарын нәтиҗәле җайга салуны тәэмин итә торган хезмәт миграциясе өлкәсендәге дәүләт идарәсенең мәгълүмат инфраструктурасын булдыру эшен дәвам итәргә.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Хезмәт базары торышын мониторинглау һәм Татарстан Республикасы икътисадының чит ил эшче көчләрен җәлеп итүдә ихтыяҗын, шул исәптән һөнәри-квалификацион состав буенча (тармаклар һәм предприятиеләр буенча), һәрьяклап бәяләү эшен дәвам итәргә.

4.2. Республика башкарма хакимияте тармак органнары һәм җирле үзидарә органнары белән бергә миграция законнарын бозуны кисәтү максатларында эш бирүчеләр, эшләргә һәм хезмәт күрсәтүләргә заказ бирүчеләр белән мәгълүмат бирү һәм аңлату эшен дәвам итәргә.

5. Республика башкарма хакимияте тармак органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм товарларны, эшләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне җитештерүнең сезонлы характерына ия булган Татарстан Республикасы предприятиеләренә, дөньякүләм тәҗрибәне исәпкә алып, сезонлы хезмәтләрдә эшләүче чит ил гражданнарына социаль шартлар һәм торак шартлары булдыру чараларын күрүне тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясенә тикшереп тору һәм күзәтчелек итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру кысаларында чит ил гражданнарына карата хезмәт законнарын, шул исәптән хезмәтне саклау законнарын, бозуны ачыклауга игътибар бирүне тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарны үтәү барышы турындагы мәгълүматны 2026 елның 30 июненә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына җибәрергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары М.Г. Әхмәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 17 июле
№ 357-VII ДС